ТАТАРСТАН
ВЕТЕРАНЫ

№ 3–4
16 март, 2022 ел

РЕСПУБЛИКА ВЕТЕРАННАРЫ (ПЕНСИОНЕРЛАРЫ) ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ СОВЕТЫ ҺӘМ «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНЫҢ УРТАК КУШЫМТАСЫ

АЗНАКАЙДА БӘЙРӘМ
Район ветераннар советына – 50 ел

> 3

ОНЫТЫЛМАС ЕЛЛАР
Сугыш чоры балалары истәлекләре

> 4

АСЫЛТАШЛАР
Мәңгәр авылында матур кичә үтте

> 7

Автор фотосы

ӘЛЕ АҢА ЙӨЗНЕ БИРМИСЕҢ...

Хәсән авылы кызы, Октябрино килене, хәзерге вакытта Кукмараның акъәбие Хәнифә Миңһаҗева күптән түгел үзенең гомер бәйрәмен – 100 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Җилкәсенә мамык шәлен япкан мөлаем әби, күзгә каршысына басып, бераз матурланды да кунакларны каршы алырга ашыкты. Якты йөзле, шаян телле, шигъри җанлы Хәнифә апа белән аралашу үзе бер күңелле хатирә булып, күңел түренә кереп урнашты.

Юбилярны котларга район башлыгы Сергей Димитриев, район социаль яклау бүлеге җитәкчесе Светлана Җамалиева, район ветераннар оешмасы җитәкчесе Валентин Иванов килеп, җылы теләкләрен җиткерде, истәлек бүләкләре тапшырды.

– Хәсән авылында – башлангыч, аннан Түбән Арбашта урта белем алдым. Җиденче сыйныфтан соң иптәшләремнең барысы да кайсы кая таралышып бетте. Унынчы сыйныфны бары тик Әхми Фәтхуллин белән икебез тәмамладык. Ул елгы балалардан хәзер мин берүзем калдым инде, – диде Хәнифә апа. – Яшьлек елларында ач тордык дип әйтә алмыйм, артык бай да, ярлы да булмадык. Әти-әни мал асрады. Әни колхозда ипи салуда эшләде, әти хуҗалык умарталарын карады, кибеттә дә хезмәт куйды. Ул бик булган кеше, авылда оста чәчүчеләрнең берсе иде. Аның муенына тубал асып йөргән вакытлары әле дә хәтердә саклана.

Хәнифә апа мәктәпне тәмамлагач, укуын Мамадыштагы милиция училищесында дәвам итәргә уйлый. Әмма сугыш тормышына үзенчә юнәлеш бирә.

> 5

Яңалыклар

Өлкәннәрне зурлыйлар

Сарман районының Азалак авылында яшәүче Мәгъриева Фатыйма Шәвәли кызына – 90 яшь.

Олуг юбилее белән ветеранны район башкарма комитеты эшләре идарәчесе Наил Сафин тәбрикләде, изге теләкләрен җиткереп, Россия Президенты Владимир Путинның котлау открыткасын, район башлыгы Фәрит Хөснуллин исеменнән истәлек бүләге тапшырды. Авыл җирлеге башлыгы Илгизәр Габделгазизов, авыл ветераннар советы рәисе Мөҗәллия Фәрлукшина, туганнары озын гомер, тигез тормыш теләделәр. Фатыймә апа тормыш иптәше Рафис абый белән 62 ел куанычлы гомер кичерәләр, бер-берсенә терәк булып яшиләр.

(sarman-rt.ru)

Тиздән һәйкәл ачылачак

Озакламый Кайбычта сугыш чоры балалары хөрмәтенә һәйкәл ачылачак. Шушы уңайдан Тәрбит авылында ветераннар советының киңәйтелгән утырышы узды. Анда авыл җирлекләрендәге ветеран оешмаларының җитәкчеләре, район башлыгы урынбасары Рәмис Хәялиев катнашты.

Җыелышта көн тәртибендәге сораулар каралганнан соң, район үзәгендә ачылачак һәйкәл төзелеше турында сөйләштеләр. Өлкәннәр үзләренең киңәш-тәкъдимнәрен җиткерделәр. Шул елларның шаһиты булган әти-әни, туганнарыннан ишеткән тетрәндергеч хатирәләр белән уртаклаштылар. Районда сугыш чоры балаларына һәйкәл халык ярдәме белән төзелә. Ветераннар советы рәисләре дә әлеге игелекле эшкә теләп кушылачакларын һәм акча җыюда булышлык күрсәтәчәкләрен белдерде.

НУРЛЫ ПАР

Тату гомер кичереп, өлкәнәйгәч тә бер-берсенең күзенә генә карап торучы, һәр эшне киңәшләшеп башкаручы парлардан илаһи нур бөркелә кебек. Кәрәкәс авылында яшәүче Рушания белән Назим Әхтәмовларга сокланмый мөмкин түгел. Зәйдә яшәгән Әхтәмовлар гаиләсе лаеклы ялга чыкканнан соң, Кәрәкәс авылына кайтып төпләнә. Хуҗабикә Рушания апа – Сарман районының Югары Әхмәт авылы кызы.

– Кәрәкәсне, аның халкын бик яратып яшим. Мондагы халыкның әйбәтлеген белсәгез иде, урамга чыксаң, бер-береңә карата шуның кадәр яхшы мөгамәләдә кәрәкәсләр, – ди Рушания апа.

Алар моннан 53 ел элек Алабугада танышалар. Яшь егет белән кыз бирелдә төзелештә эшли. Бер-берсен бер күрүдә үк ошаткан Назим белән Рушания 18 яшьтә гаилә дә коралар.

– Безнең өйләнешкән көнебез гади генә дата түгел, 1969 елның 16 декабрендә Чаллыда КамАЗ заводының беренче грунты алынды, бу – нәкъ без язылышкан көн, – ди Әхтәмовлар. Ә аларның хезмәт юллары шул заводның бер өлеше булган Зәй автоагрегат заводына бәйле. Назим абый «Гидромонтаж»да 20 ел эретеп ябыштыручы булып эшләп, аннан автоагрегат заводына күчә, ә Рушания апа автоагрегат заводында кассир булып хезмәт куя. Аларның яшьлекләре данлы, бөек төзелешләр чорына туры килә.

Ә инде авылга кайткач, төп нигездә йортны, хуҗалыкны яңартып яши Әхтәмовлар. Бакча үстерәләр, умартачылык белән шөгыльләнәләр.

– Умартачылык безне үзенә шулкадәр бөтереп алып кереп китте. Назимнар яшь чакта да умарта тотканнар. Тик мин бу эштән бик куркып калдым. Назимның туганы, авылыбызның зур хөрмәткә лаек шәхесе Фаиз абый Гомәров: «Безнең нәсел гомер-гомергә умарта тотты, нәрсәсеннән куркасың аның, үзең тимәсәң, кортлар сиңа тими», – диде. Шуннан, тәвәккәлләп, бу эшкә алындык. Яраткан эш белән шөгыльләнү күңелгә рәхәтлек бирә, шатлык китерә, – ди Рушания апа.

Бакчаларында нинди генә чәчәкләр, җимеш агачлары үсми аларның!

– Миңа бакча эшләрендә Назимның җизнәсе Рәфкать Шәвәлиев булыша. Бөтен эшемне аның белән киңәшләшеп эшлим, бакчадагы барлык җиләк-җимеш агачлары җизни биргән, – ди Рушания апа.

Әхтәмовларның ишекләре һәрчак туганнары, дуслары өчен ачык. Назим абый – нәселенең патриоты. Әти-әнисен, туганнарын хөрмәт итеп яши, бабалары турында мәгълүмат барлап тора. Алар – Төхвиләр нәселеннән, ә бу нәсел Кәрәкәстә, тирә-як авылларда хезмәт сөючән, акыллы, тырыш булуы белән данлыклы. Сабантуйларда Әхмәтовлар нигезе гөрләп тора. Барлык туганнарын бәйрәмгә җыеп, хөрмәт итәләр. Бер елны хәтта 36 кеше җыелган идек, ди Рушания апа.

– Гомеребез бәхетле узды дип саныйм. Тату яшәдек, эшләп ашадык. Рушания барлык эшемдә ярдәмчем булды. Бүген төп нигездә туганнар, балалар белән еш җыелабыз. Бәхет – шул инде ул, – ди гаилә башлыгы Назим абый.

Алардан: «Авыл тормышын шәһәргә кире алмаштырыр идегезме, фатирыгызга барып яшисегез килгән көннәр булмыймы?» – дип сорыйм.

– Юк, авылны ташлап, шәһәрдә бер көн дә куна алмыйм. Кәрәкәсне үз итеп яшибез, – дип җавап бирде алар.

Бүген Әхтәмовлар өч балаларына, өч оныкларына, бер оныкчыкларына куанып яши. Барына да өлгерәләр! Эшләргә дә, ял итәргә дә, рухи азык тупларга да! Бер-берсен мактап куярга да...

ӘЛМӘНДӘРГӘ ТИҢ БАБАЙ

Татар туенда кияүнең каенишләренә пәке бүләк итүе – таралган күренеш. Гадәттә, пәке егет тарафыннан авыл капкасын ачу белән каенишләренә тапшырыла.

Мондый пәке Кәрәкәс авылында яшәүче Фаиз абый Гомәровта да саклана. Бу пәкене Фаиз абый җизнәсе бүләге итеп саклый. Ул узган гасырның 50 нче елларында кияү бүләге итеп Фаиз абыйга бүләк ителгән.

Кияү пәкесе символик мәгънәгә ия, чөнки борын-борыннан егет кешенең кесәсендә пәке йөрүе табигый күренеш булган. Пәке үзенә күрә ир-егетлек символы вазыйфасын башкара. Кияүнең каенишенә пәке бүләк итүе аны үзенең тиңе итеп, егет итеп исәпләвен дә күрсәтә һәм ике арада тигез, дустанә мөнәсәбәтләр урнашуга нигез була.

Фаиз Гомәр улы 1930 елда Кәрәкәс авылында дөньяга килә. Ул – сугыш чоры баласы да, тыл ветераны, гомер буе укытучы булып эшләгән 42 ел стажлы хезмәт ветераны да. Алар гаиләсендә дүрт бала үсә. 1916 елгы абыйсы Лотфурахман Бөек Ватан сугышында хәбәрсез югала. Сугышка киткәнче ул Фаиз абыйны гармунда уйнарга өйрәткән, әдәби китапларны күп укырга әйтеп калдырган.

Фаиз абый белән тормыш иптәше Әлфия апа бер-берсен туганнан бирле беләләр, чөнки бер авылда үскәннәр, яшь аралары да – өч кенә ай. Гомәровлар килгән шатлык-куанычларны, авырлык-сынауларны бергәләп күтәреп, дүрт малай үстереп, яшәүнең мәгънәсен, тормышның кадерен белеп, тирә-юньдәгеләргә үрнәк булып, 64 ел бергә матур гомер кичерделәр. (Кызганыч, бүген Әлфия апа мәрхүмә инде.)

1945 елда алар икесе дә Алабуга педагогика уку йортына укырга керәләр, 1950 елда аны тәмамлап, 4 елдан тормыш корып җибәрәләр.

Фаиз абый – тормыш баскычларының төрлесеннән үтеп, сынауларда сыналмыйча, мактаулы исемнәргә лаек булган кеше. Авылда аны бик хөрмәт итәләр. Картая белмәүче, тиктормас остаз-ветеран һаман да безнең арада. Клубта оештырылган бәйрәм-кичәләрдә, утырышларда бик теләп катнаша, чыгыш ясый, яшь буынга тәрбия бирүдә өлешен кертә. Аның ярдәмендә авылда күп кенә эшләр башкарыла. Ул һәрвакыт ачык йөзле, киң күңелле, кешеләрне ярата, кеше гозерен беркайчан да кире какмый, ярдәм итәргә тырыша.

Фаиз абыйга – 91 яшь. Тик тормас, тынгы белмәс, үткен зиһенле, шук-шаян, Әлмәндәргә тиң бабай ул!

Клара ЕРМОЛАЕВА әзерләде

Киң күңелле Кәримә

Куш-Елга авылында гомер итүче Кәримә апа Закирова 90 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Әбиләрен котларга оныклары чәчәк бәйләме һәм тортлар белән кайтып керделәр. Авылда хөрмәткә лаек ветераннарның берсе ул Кәримә апа.

– Сугыш һәм аннан соңгы авырлыкларны күргән, газиз баласын югалту ачысын татыган Кәримә әби бүген дә хөр, аек фикерле, җиңел гәүдәле әле. Йорт-җире, ишегалды караулы, тәртиптә. Балалары, оныклары кайтып булышып торалар, – ди авыл китапханәчесе Розалия Әхатова.

Кәримә апа гаиләдә дүртенче бала булып туа. Дүрт класс белемне туган авылында ала, авыр сугыш еллары булу сәбәпле, кабат укырга барулар насыйп булмый инде, колхозда төрле эшләрдә эшли. Сугыш башланганда абыйсы Шәкертҗан армия сафларында хезмәттә була, шуннан сугышка алалар. Сугыштан, яраланып, туган авылына кайта, шунда гаилә корып яши.

Кәримә апа Куш-Елганың уңган егете Махиян белән гаилә кора. Тату, матур, үрнәк гаиләдә дүрт бала үсә. Әле бертуган апасы Гыйльменурның 2 онығы гел шушы гаиләгә килеп йөриләр. Бу балаларның әниләре авариягә очрап һәлак булган. Алар гаиләсенә дә булышып, бергә тату яшиләр. Кәримә апа авылда урманнан иң оста җиләк, чикләвек, шомырт җыючыларның берсе булды.

Хәзерге көндә Кәримә әбинең 8 онығы, 8 оныкчыгы бар. Бәйрәм, ял көннәрендә ветеранның йорты гөрләп тора.

МИРГАСИМ КӘРИМОВ:

«ВЕТЕРАННАР ТИК УТЫРМЫЙ»

Быел республикада ветераннар советы оешуга 35 ел тула. Ә безнең районда бу оешма күпкә алдан – 1972 елда ук төзелеп, быел инде үзенең 50 еллыгын билгеләп үтә. Аның ике дистә елга якын альштыргысыз җитәкчесе Миргасим КӘРИМОВ белән әңгәмәбез – менә шушы озылган юлның истәлекле вакыйгалары, өлкәннәребезнең бүгенге сулышы хакында.

:: Миргасим Ильясович, бераз гына тарихка күз салып, әнә шул җитмешенче елларга кайтып килик әле.

– 1972 елның көзендә КПСС райкомының беренче секретаре Әнвәр Баһаутдинов инициативасы белән бер төркем активистлар – Фәйзи ага Зиннуров, Хафиз Әүхәдиев, Мөгыйн Мортазин, Мөҗәһит Мөстәкыймов, Кәшиф Хәкимов, Маузер Хәкимов ветераннарның иҗтимагый оешмасына нигез сала. Республикада иң беренче булып төзелгән оешма була ул. Районнашыбыз Гали Садыйков та ветераннарны бер йодрыкка туплауда оештырып йөрүче активистларның берсе була. Хезмәт коллективларында бер-бер артлы беренче ячейкалар барлыкка килә. Берничә эресенә генә тукталып, «Азнакайнефть»тә ветераннар оешмасын Сәгытдин Фәттахов, «Актүбәнефть»тә – Габдрахман Гыйльманов, «Сельхозтехника»да – Хәниф Галәветдинов, Югары Стәрледә – Сабир Галләмов, Үчәлледә – Мәсгут Газизов, Вахитов исемендәге совхозда – Александр Сафронов, Урманайда Хәбиб Хәйдәровның җитәкчелек итүен әйтеп үтәргә кирәк. 1973 елның 10 декабрендә район ветераннарының беренче конференциясе уза. Ул чагында пенсионерлар саны 10 меңнән артык була, отчет докладында алар арасындагы активистларның бер ел эчендә укучылар һәм яшьләр белән 40тан артык очрашу үткәрүе, аларда 9 меңнән артык кешенең катнашуы, 9 ветеранның авыр тәрбияләнүче балаларга беркетелүе хакында әйтелә. Беренче конференциядә ветераннар советының рәисе итеп Фәйзи Зиннуров, аның урынбасары Кәшиф Хәкимов, секретаре итеп Банат Галиева сайлана. Фәйзи Зиннурович оешма белән тоташтан 10 ел җитәкчелек итә. Аннан соң оешма башында 4 ел Ярхәм Хисамов, 7 ел Фатыйх Галиев, 11 ел Габделхәй Рәхимов тордылар. Минем бу вазыйфага алынганга да инде – 17 ел. Шушы еллар дәверендә оешма бик күп үзгәрешләр кичерде, ветераннарның районда иҗтимагый роле тагын да үсте, абруе артты, эшчәнлегебез тагын да киңәйде.

:: 20 меңгә якын кешене берләштергән оешманы идарә итү – сүз дә юк, зур җаваплылык кына түгел, тәвәккәллек тә ул. Районның иҗтимагый тормышын халыкның 30 процентын тәшкил иткән ветераннардан башка күз алдына да китереп булмый. Шушы эшчәнлек турында сөйләп узсагыз иде.

– Әйе, ветераннар – зур көч, бәһасез тәҗрибә чыганагы, җәмгыять тәрбиячеләре, остазлар, яшь буын өчен олы үрнәк, таяныч, киңәшчеләр. Көзге һәм язгы кыр эшләре чорында авыл хезмәтчәннәренә ярдәм оештыру, мәктәпләрдә әхлакый-патриотик чаралар үткәрү, районда уздырылган һәртөрле очрашулар, бәйрәмнәрдә катнашу, яшьләрне хәрби хезмәткә озату – болар районыбыз өлкәннәре тарафыннан башкарылганнарның беразы гына. Ә инде Бөек Җиңүнең 75 еллыгына һәм аннан соңгы истәлек даталарына алып барылган әзерлек республика күләмендә үрнәк итеп куелды, бу бәйгедә лаеклы җиңү яуладык. Республиканың ветеран төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Хәбир Иштирәковның районыбызга визиты вакытында эшчәнлегебезгә зур бәя бирүе барыбызда да, бердән, горурлык хисләре уятса, тагын да яхшырак эшләргә дәрт өстәсә, икенчедән, республика күләмендә яуланган биеклекләрне, позициябезне югалтмауда тагын да җитдирәк бурычлар өстәде.

«Халык контроле» составында сыйфат инспекторлары вазыйфасы йөкләнгән элеккеге хуҗалык җитәкчеләре, авыл хуҗалыгы белгечләренең хәзер дә бу өлкәне үстерүдә өлеше бәһасез. Алар кыр эшләре сыйфатын күтәрүдә авыл хезмәтчәннәре, җитәкчеләре белән бергә янып-көеп йөри. Азнакайга бер килүендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та бу эшчәнлекне республиканың авыл хуҗалыгы гына түгел, промышленность өлкәсендә дә өлге итеп куярга кирәклеген әйткән иде. Безнең «Халык контроле» әгъзалары кайсы дәвердә дә актуаль булган медицина хезмәтен дә күз уңыннан төшерми. Шикаятьләр аеруча күп кергән бүлекләрдә җитешсезлекләрне ачыклау, аларны уңай якка хәл итүдә аларның өлеше зур.

Безнең өчен һәр кеше кадерле, ә инде сугышны кичергән, илгә Җиңү яулаган ветераннарыбыз бигрәк тә. Аларга исән чакта кадер-хөрмәт күрсәтеп калырга тырышабыз, гаилә бәйрәмнәре, туган көннәре белән өйләренә барып котлыйбыз. Без, ветераннар советы әгъзалары, һәр ветеран белән даими элемтәдә. Тик менә соңгы еллардагы коронавирус пандемиясе генә мондый аралашуларны чикләде. Бу чорда үзләре янына бара алмагач, телефон аша хәл-әхвәлләрен белешеп тордыбыз, ялгыз яшәүчеләргә көнкүрешләрендә ярдәм итәбез.

Мине ветераннар советына рәис итеп сайлаганда, фронтовиклар 450ләп кеше иде. Еллар үтә торды, аларның да саны кими барды. Мин сугыш солдатларының һәммәсен соңгы юлга озатуда үзем катнашырга тырыштым. Хәзер инде нибары 8 кеше калды, шуларның икесе – хатын-кыз. Инде шактый олы яшьтәге бу ветераннарыбыз – сәламәтлекләре буенча инвалидлар, күпләре түшәктә. 801 тыл ветераны яши. Җирлегебездә Бөек Ватан сугышы каһарманнарына куелган 60тан артык һәйкәл бар. Алар чистартылып, төзекләндереп торыла. Районыбызда 4,5 мең сугыш чоры баласы исәпләнә. Аларның да инде иң яше сиксәнгә җитеп килә. Сугыштан соңгы җимереклекләрне торгызу, җирлегебезне үстерү, яшь буынны тәрбияләү тулысы белән менә шушы буын җилкәсенә төшә. Алар хәзер дә актив. Мисал өчен, Ленин ордены кавалеры Әнис Лотфуллин тырышлыгы белән күпләргә үрнәк. Сәгадәт Шәйхиев ел саен үз умарталыгында алган балдан инвалидларга өлеш чыгарып тора. Нурулла Гобәйдуллин (ул тарихи китап та иҗат итте), Азат Харисов, Рудис Сәлахов, Ирек Әхмәтов, Фаяз Хәбибуллин, Нәсимә Камалиева, Илдар Сәмигуллин мәктәпләрдә укучылар белән патриотик тәрбия эшен җәелдерделәр. Альбина Сафиуллина, Мәрзия Бүләкова, Сирена Галиева, Мәйсәрә Хафизова, Галия Хәева, Гөлүсә Кәлимуллина кебек активистларыбыз, коронавирустан саклану өчен, чордашларына, күршеләренә битлекләр тегеп тараттылар. Мондый тынгысызларыбыз исемлеген әле бик күп дәвам иттереп булыр иде.

:: Соңгы елларда күп кенә яңа башлангычларга нигез салынды, аларны да барлап китик әле.

– Ветераннар өчен Сабантуйлар үткәрү шулай ук Азнакайда башланып киткән иде. Пандемиягә кадәр ел саен ул югары дәрәҗәдә, өлкәннәребезнең күңеле булырлык үтте. Туймазыдан, үзебезнең күрше районнардан да кунаклар килде. Республикада беренче тапкыр районыбызда аталган хезмәткәр исеменә һәм башка югары дәүләт бүләкләренә ия булганнарны хөрмәтләү тантанасы уздырылып, янә бер матур йолага нигез салдык. Төрле елларда районыбызның колхоз-совхозларын 20 елдан артык җитәкләгән, республика күләмендә танылган шәхесләребез исемнәрен мәңгеләштерү инициативасын да хәзерге җитәкчеләребез, бигрәк тә район башлыгы Марсель Шәйдуллин хуплап алды, бу идеяне тормышка ашыруда ярдәм күрсәтәләр. Шул рәвешле, бүген Фердинанд Ягафаров, Каһәгать Газизуллин, Габделхәй Рәхимов, Сәгадәт Аппаков, Гарифҗан Галимов, Мират Гыйләҗетдинов хөрмәтенә алар рәис булып эшләгән хуҗалыклар җирлегендә, Рафаил Сафин, Евдокия Калинина, Леонид Маркензон, Хәләф Хәмзин һәм башкаларга шәһәребездә мемориаль такталар куюу тантаналары узды. Легендар шәхесләребезнең исемнәрен мәңгеләштерү дәвам итә.

Көзге матур фасылда Әбиләр чуагы, Самавыр бәйрәмнәре үткәрү дә безнең Азнакай җирлегеннән башлангыч алган иде. Бездә күреп киткәч, аларны күрше-тирә районнарда да бик яратып үткәрә башладылар. Районның 90 еллыгына багышланган китап нәшер итүгә, югалган авылларны барлап, зиратларны төзекләндерүгә, аларның тарихын китап итеп туплауга өлкәннәребезнең зур өлеше керде. Бетерелгән оешма-предприятиеләр пенсионерларын барлап, аларның ветераннар оешмаларын төзедек. Хәзер инде берәү дә читтә калмый, һәр өлкән кеше безнең ярдәм-кайгыртуда. Ветераннарыбыздан тупланган иҗат төркемнәре районыбыз тамашачысы күңелен генә түгел, республика сәхнәләрен дә яулап, бәйгеләрдән җиңүләр белән кайтлар.

Әңгәмәдәш – Нәсимә КАМАЛИЕВА

«УЛ ВАКЫТЛАР ӘЛЕ ДӘ ОНЫТЫЛМЫЙ»

Бөек Ватан сугышы елларында хатын-кызларыбыз күпне кичерде. Алар үз иңнәрендә бик күп авырлыкларны күтәрделәр. Язмаларыбыз – балачаклары шушы авыр сугыш елларына туры килгән апа-әбиләр хакында.

«СИГЕЗ ТӨРЛЕ ҮЛӘН АШАДЫК»

Шулай дип искә ала үзенең балачагын Яңа Кәкерле авылында гомер кичерүче Кәүсәрия Арифулла кызы Садыйкова. Аңа шушы көннәрдә 90 яшь тулды.

Кәүсәрия апа үзенең сугыш белән үрелеп үткән балачагы турында болай дип сөйли:

– Сугыш вакытында без кечкенәрәк идек, шулай да әниләр белән утаудан, әз-мәз булышып йөри торган эшләрдән калмадык. Ә инде мәктәпне тәмамлагач, без «зур кеше»ләр исәбенә кердек. Мәктәпне тәмамлауга, фермага эшкә киттем: дүрт ел җәй көне «Бакырлы елгасы»на кадәр җәяү йөреп, сыер саудым. Аннан соң ике кыш Тархан урманнарын кистек. Шул эшләргә бергә йөргән кызлардан бүген мин генә исән, барысы да вафат булды инде. Эшләмәгән эш калмады, дисәм, тракторга гына утырмадым. Без күргәннәрне сөйләсәң, кем дә ышанмый. Аларны күрергә дә язмасын. Ачлык күрдек, шул елны сигез төрле үлән ашадык, шуңа үлмәдек. Эти сугышта иде, әни нужа белән булса да сыер асрады, шул коткарды безне ачлыктан. Үлән ашау еллары беткәч, бәрәңге уңды авылда. Халык бераз ачлыктан котылды. Кырда кабак кабыгына эләгеп егылырлык була иде. Ник дисәң, бөтен кеше бәрәңге, кабак пешереп бара иде кырга салам җыярга. Картлыгыбызда менә рәхәт тормышта яшәргә насыйп булган, Ходай Тәгаләнең рәхмәте бу.

Кәүсәрия апа авылдашы Нургасимга тормышка чыга. Алар икесе дә әтисез, ятим үсәләр. Нургасим абый армиядә дүрт елга якын хезмәт итеп кайта. Өйләнешкән елларын искә алып, Кәүсәрия апа үзләре белән бер вакытта, 1958 елда, авылда 5 парның гаилә коруы турында сөйли. Ә үзе Нургасимыннан ике яшькә олырак була. «Мин бит олы синнән, картлык та миңа иртәрәк килер, яратмассың аннан», – димен. Ә ул: «Үзем теләп алам, яшь итеп сакларга тырышырмын», – диде.

Алар бик бәхетле яшиләр. Дүрт балага гомер бирәләр. Кәүсәрия апа бәхетле картлыгында онык, оныкчыкларын сөя. 60 ел бергә яшәгән Нургасимы дүрт ел элек вафат булган.

– Әллә ни зур буйлы, «эре» кешеләр булмасак та, тырыштык. Йорт җиткездек, колхозның бер эшеннән дә калмадык. Бабаем да уңган, яхшы булды, – ди Кәүсәрия апа.

Аның зиһененә, һәрбер вакыйганы истә тотып сөйләвенә исең-акылың китәр. Хәтта җитәкчеләрнең, ул чорда эшләгән хезмәттәшләренең дә барысын да исем-фамилияләре белән атый.

Юбилее уңаеннан аны хакимияттән дә олылап килделәр. Район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Илһам Бикчуров һәм авыл җирлеге башлыгы Радик Мөхәммәтҗанов Россия Президентыннан котлау, район башлыгыннан бүләкләр тапшырдылар. Исәнлек, тынычлык, хәерле гомер теләделәр.

«90 ЯШЬКӘ ҖИТҮ – БӘХЕТ УЛ»

Кече Чынлы авылында гомер кичерүче Рокия Аляутдин кызы Мифтяхова өчен язның беренче көне юбилейлы гомер бәйрәме – 90 яшьлеге белән башланып китте.

Рокия апа үзенең балачагын бернәрсәсез, урамда яшәп калулары белән хәтерли.

– Безнең гаиләне кулаклар дип, урамда бастырып калдырдылар. Аннары безне бер бабай үзенең балчык ызбасына кертте. Идәне саламнан иде. Күп тә үтмәде, әтине сугышка алып киттеләр. Әтигә сугышка китәргә дигән кәгазьне бер олырак яшьтәге абзый безгә биреп калдырган иде. Икенче көнне үк алып та киттеләр. Бу 1941 елның 29 июле иде, – дип сөйли ул.

Рокия апалар гаиләдә дүртәү булалар. Ә Миргалие белән ул үзе 6 бала тәрбияләп үстерә. Дүрт малай һәм ике кыз. Төпчекләренең армиядән кайтуын күрә алмый гаилә башлыгы, бакыйлыкка күченә. Рокия апа исә ике баласын югалту хәсрәтен аннан башка гына күрә. Каенанасын, сугыш кичкән каенатасын да карап-тәрбияләп торып, соңгы юлга озата ул.

– Икебез дә колхозда эшләдек. Йорт салдык, кешедән ким-хур яшәргә тырышмадык, – ди акъәби.

Бүген Рокия апа янында улы Илгиз һәм килене Лилия – төп таянычы, уң кулы булып яшиләр. Бер оя булып тора башлауларына да 30 еллап вакыт узган.

Рокия апа тормышында нинди генә сынаулар аша узса да, зарланмый. «Ходай Тәгалә сынавы барысы да. Сынавын да, ярдәмен дә бирүче ул», – ди.

90 яшенә җитүен дә олы бәхет дип саный.

– Балаларымның балаларын, оныкчыкларны күрергә насыйп булды, бәхет бит инде бу, – дип куана.

Аның гомер бәйрәменә дә котлаулар, бүләкләр белән район Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Сатдинов, авыл җирлеге башлыгы Гомәр Халитов килделәр. Россия Президентыннан котлау, район башлыгыннан бүләк, чәчәкләр тапшырып, иң изге теләкләрен юлладылар.

Гөлия ФӘИЗОВА.
Чүпрәле районы

Күңел күзе алдамый

95 яшьлек Рәйсә апа Кыямова әле дә йорт алларында кар көрәп, сукмак салып йөри, эштән курыкмый. Дөрес, кыз туганының балалары аңа эш кушмый, кадерләп кенә торалар үзен.

– Инде ун ел чамасы апа янында без, – ди Гөлйөзем Хәйруллина. – Ирем Мингаяз былтыр вафат булды. Улыбыз Айрат бу өйне нык матурлады, Ходай язса, тышкы якны да яңартырбыз дип торабыз.

Яшь чагында үгез җигеп йөк ташыган, урак урган, фермада эшләгән Рәйсә апа берүзе икешәр тонна суган үстереп тә таныла. Олыгайгач, Утыз Имән авылында дини йолаларны саклауга зур өлеш кертә, мәҗлесләрдә сүрәләр укый, дога кылып, мәрхүм-мәрхүмәләр рухын сөендерә.

– Мин өч алфавит беләм, латин графикасында да укый алам, – ди ветеран. – Немесчәм дә бар, ул телдә йөзгә хәтле санарга өйрәндем. Мактаныйм әле, элек табыннарда башлап җырлаучы да булдым.

Рәйсә апа туган көнендә дә матур итеп җырлап җибәрде.

– Рәйсә җырламыйча тора алмый ул. Гомер буе бергә, аралашып яшәдек, – ди ахирәтен котларга кергән Рәхилә апа.

Ә Канадада яшәүче туганы – Рәйсә апаның энесенең кызы Клара юбилярны телефоннан шалтыратып тәбрикләгән. Авылда яшәүче туганы Гөлия Гыйрфанова бәйрәм табынына бик тәмле бәлеш пешергән.

– Рәйсә апаны әле кайчан гына 90 яше белән котлаган идек. Йөз яшьлек юбилеена да килергә язсын, – диде районның социаль яклау бүлеге җитәкчесе Рушания Әхмәдуллина.

Язмыштыр инде, яшьрәк чакта гаилә кора алмаган Рәйсә апа. Алай да төшенкелеккә бирелмичә яшәгән, эшләгән. Нибары бер тапкыр хастаханәгә барган. Бүген дә зарланмый әле. Күзләре начар күрсә дә, күңел күзе алдамый аны. Ул үзенә игелек кылган һәр кешегә дога укып утыра.

Кадыйр ГОМӘРОВ.
Чирмешән районы

Әле аңа йөзне бирмисең...

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Студент егет-кызларның барысы диярлек укуларын ташлап китәргә мәҗбүр булалар. Ун сыйныф белеме булгач, Хәнифә апаны балалар укытырга билгелиләр.

– Авылларда укытучылар җитми иде, минем гаиләм булмагач, әле бер, әле икенче җиргә эшкә җибәрделәр, җиде авыл буенча йөрдем, – диде ул. – Бу хезмәткә җиде ел тирәсе гомеремне багышладым. Шуннан соң Октябрино авылына кияүгә чыктым, дөресрәге, булачак ирем мине урлап алып кайтты. Миннәхмәт бик акыллы, тәртипле кеше булды, без аның белән өч ул, бер кыз тәрбияләп үстердек. Аллага шөкер, барысы да исән-саулар. Ирем сугыш ветераны, танк йөрткән, сәламәтлеге нык какшаган иде. Ул 74 яшенә җитеп бакыйлыкка күчте.

Алар, тормыш иптәше белән төрле җирләрдә йөреп, бәхетләрен сынап карыйлар: Лесхозда, Иштуганда, Пермь өлкәсендә гомер итәләр. «Кайда яшәсәң дә, күршең үзеңнән яхшырак булсын, диләр. Безнең юлыбызда һәрвакыт якты күңелле кешеләр туры килде», – диде ул. Хәнифә апа балалар бакчасында хезмәт куя, ире урманчылыкта эшли. Ә лаеклы ялга чыкканнан соң алар Кукмарага кайтып урнаша.

Хәнифә апа, Аллага шөкер, хәзергә көндә дә туган нигезем исән-сау, дип сөенә, моның өчен ул туганнарына рәхмәтле. Үзе дә җәй көннәрендә авылга кайта, зиратка бара. Йөзьяшәр әби белән озын гомерлелекнең сере турында да сөйләштек.

– Бу тормышта яшисе килеп яшәргә кирәк. Сугыштан соң авыр булды, әмма алар онытыла, хәзер тормышлар әйбәт бит. Аллаһы Тәгалә – мине, мин аны онытмыйм. Күз күрә, аякларым йөри, Ходай сәламәтлекне бирде, – диде ул. – Минем әтием ягыннан бабам да озын гомерле булган. 108 яшенә җитеп бакыйлыкка күчте, күзе күрми иде, әмма тән авыртуларыннан зарланганы булмады. Ул гел: «Минем бер җирем дә авыртмый, күзем күрсә, чабата бәйләп кенә утырыр идем», – ди иде.

Акъәби хәзерге көндә кызы Кадрия апа белән кадер-хөрмәттә гомер кичерә. Ул мәктәп елларыннан алып шигырьләр язарга яраткан, аны туган көннәре хөрмәтенә күршеләренә, туганнарына багышлаган. Тик соңгы вакытта гына язуым бераз ямьсезләнде, ди. Хәзер исә буш вакытында газеталар укый, телевизор карый. Аеруча балаларга багышланган тапшыруларны ярата, шул ук вакытта яңалыкларны да читтә калдырмый.

– Әни һәрвакыт яхшы күңелле, олы йөрәкле булды. Мин аның кеше белән талашканын, сүзгә килгәнен хәтерләмим, шуңа күрә күршеләр белән дә бик тату тордык. Ул һәрвакыт хәрәкәттә, әле дә үзен карап-тәрбияләп тора. Җәй көне бакчадан керми, хәтта агач ботакларына хәтле пычкы белән үзе кисә... Эшләп яшәсәң, тормышта бар да була, ди ул. Безне дә хезмәткә өйрәтеп үстерде, рәхмәт аңа. Күз тимәсен, әни белән бик рәхәт гомер итәбез, алга таба да исән-сау торырга язсын.

Ризилә КОРБАНОВА.
Кукмара

Хәбәрләр

Бәйрәм түгел, эш кирәк!

Тәтеш районының Байраш авылында яшәүче Фатыйма Әминова әнә шулай ди. Күптән түгел ул «Ана даны» медаленә ия булган. Фатыйма апа Апас районында туган, аны Тәтеш районы егете урлап кайткан. Бергә яшәүләренә дә 40 ел инде.

– Башта колхозда товарлыклы-сөтчелек фермасына бозау караучы булып эшкә кердем, берни белми идем, хезмәттәшләрем әйбәт кабул иттеләр, өйрәттеләр, бездә халык яхшы, – ди Фатыйма апа. – Аннары хуҗалыкның бозаулату бүлегендә, шуннан соң сыер савучы, склад мөдире булып эшләдем, ирем Дамир ясалма орлыкландыручы вазыйфасында хезмәт куйды. Без күп вакытны эштә уздырдык, ә биш балабыз мөстәкыйль булып үстеләр, безгә һәр эштә булыштылар, бер-берләрен карадылар.

Ир белән хатын йорт хуҗалыгында һәрвакытта мал-туарны күп асраганнар, лаеклы ялда булсалар да, авылча яшәү гадәтен дәвам итәләр, аларның ике сыерлары бар, артып калган сөтне җыючыга тапшыралар, үгез, тавыклар тоталар, җәй көне башка кош-кортлар да үстерәләр. «Бәйрәмчә яши алмыйбыз, эшләргә күнеккәнбез», – диләр Әминовлар.

«Тәтеш таңнары»

ЧИГҮЧЕ ФӘРИДӘ КӘРИМУЛЛИНА:

«ЭНӘ ТОТСАМ, ОНЫТЫЛАМ»

Эшсез торсам, үземә урын тапмыйм. Арчада яшәүче 64 яшьлек кул эшләре остасы әнә шулай ди. Гомере буе чигү чиккән ул. Мәктәпне тәмамлауга, «Арча милли киемнәре» оешмасына эшкә килә. Бик яратып эшли башлый. Әмма оешма 2006 елда ябыла.

– Шуннан соң безне эшмәкәр Айрат Солтанов үз канаты астына алып, тагын эшли башладык. Ул үзе безгә читек, чүәкләрнең өлгесен кисеп бирә иде. Без аны чигә идек. Әмма ул да озак эшләмәде, без яңадан таралыштык, – ди Фәридә апа.

Әнә шуннан соң ул өендә үзенә эш урыны көйләтеп куя. Әкренләп заказлар кабул итә башлый. Оста куллы икәнен белеп алгач, эш бирүчеләр аны үзләре таба. Заказ арты заказ килеп кенә тора. Пенсиядәге кешегә өстәмә акча да комачау итми. Җитмәсә, гомере буе эшләгән эше бит! Тик бер ягы бар – гел энә-җеп тотып, күзләренә зыян килә. Шуңа да Фәридә апа хәзер күзлек киеп эшли икән.

– Берьюлы өч кеше белән эшлим. Берсе сумкалар чиктереп ала, икенчесе – аяк киемнәре, өченчесе мендәрләргә бизәк чигеп бирүемне сорый. Безнең эш башкачарак. Кульяулык чигү генә түгел. Бер кулда – машина энәсе, икенче кулда – башкасы. Без аны «чирмеш энәсе» дип йөртәбез. Шулар ярдәмендә орчыктагы җепне чигеп, аннары бизәкләрне тоташтырабыз. Чигүне аңлар өчен үзеңә карап торырга кирәк, – ди Фәридә апа.

Баксаң, ни чиккәнен ул үзе дә күрми икән. Сул яктан эшлиләр, бизәк уң якка чыгып бара.

– Заказлар күп булганга сөенәм генә. Җәен бакчада эш күп булгач, кайчак эшләми дә торам. Әмма бик үтенеп сорасалар, чигүгә вакыт табам. Кышын инде рәхәтләнеп эшлим. Өйдә алай эш күп булмый. Нишләргә кирәк тагын? Әгәр кул эше дә тотмасаң, көнне уздырып булмый. Эш белән гомер узганы да сизелми. Чигүгә тотынсам, җаныма тынычлык табам, – ди Фәридә апа. – Ә инде эшем өчен акча түләнгәч, күңел сөенә. Пенсиядә килеш акча эшли алуыма шатланып бетә алмыйм. Әле киләчәктә дә, сәламәтлегем бер килеш торса, кул эшемне ташламаска уйлыйм. Үзем кебек өлкәннәргә киңәшем шул – кул эшләренә тотыныгыз. Җанга ял алуга ни җитә!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Гали абыйга – 90

Районыбызның үткәне һәм киләчәге турында фикер алышу, күрешү, аралашу өчен яхшы бер сәбәп чыгып куйды. Гали Җәләловка 90 яшь тулды. Әнә шул уңайдан без аны тәбрикләп кайттык. Гали абый – озак еллар электрлаштыру өлкәсендә эшләгән кеше. 1950 нче еллар ахырында Буа халкын Яңа ел чыршысын электр гирляндалары белән бизәп шаккатырган кеше ул. Лаеклы ялга чыккач, район һәм шәһәр рухи тормышы өлкәсендә актив эш алып бара башлый. Буаның беренче мәчетендә аның беренче имам-хатыйбы булып күп еллар эшли. Хатыны Хава белән бергә 65 ел матур гомер кичерәләр. Алар биш балага гомер бүләк иткәннәр, алты онык һәм биш оныкчыкның шатлыкларына куанып, балаларының рәхәтендә бәхетле картлык кичерәләр.

Җәүһәрия ХӨСНЕТДИНОВА,
район ветераннар советы рәисе

МАЛ ТАБИБЫ

«Татарстан» совхозы поселогында туып-үскән Гатифә Гәрәева, Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлагач, шул ук районның Кадрәк авылында яшь белгеч буларак хезмәт юлын башлый. Терлекчелек тармагы баш ветеринары Габбас Сабирҗанов кулы астында эшләп тәҗрибә туплаган зоотехник кыз 1958 елда Ирек Таңы авылына килен булып төшә һәм сайлаган һөнәренә гомере буе тугры кала.

– Ирек Таңы бик матур бит ул. Халкы әйбәт. 63 ел шушы авылда яшәгәч, үземне шушында туып-үскән кебек хис итәм. Гомер буе колхозда зоотехник, ветеринар булып эшләгәч, малы чирләп киткән кешеләр тәүлекнең теләсә кайсы вакытында ярдәм сорап киләләр иде. Мал да, кеше сыман, күзеңә карап ярдәм көтә. Элек бит ул һәр хуҗалыкта кимендә бер, ә инде күпчелегендә икешәр сыер асрала торган иде. Сыеры бозаулый алмагач, төнлә ишек кагучылар да байтак булды. Авыр хәлдә калган сыерларның мөлдерәп торган күзләрен күргәч, төнге йокыларың ачыла. Бозаудан исән-имин котылган сыерның рәхмәт тулы күзләренә карагач исә бар авырлыклар да онытыла. Кемгә дә булса кирәклегеңне тою күңелне үстерә, – ди ферма мөдире, ветеринар, зоотехник хезмәтләрен яратып башкарган Гатифә апа. Аның тормыш иптәше Вәсил Гәрәев иген иккән, басу-кырлар эшкәрткән. Өч бала тәрбияләп үстергәннәр. Уллары Фәһим белән Илшат, кызлары Гөлүзә – илгә-көнгә игелекле, гаилә җанлы кешеләр. Гатифә апаның җиде оныгы һәм ун оныкчыгы бар. Балалары, оныклары җәй чыккан саен Ирек Таңына әбиләре янына кайтып йөриләр.

– Бар иде заманалар, фермаларда, басу-кырларда эш гөрләп барды, – дип сөйли авылның өлкәннәре. Ирек Таңы кечкенә дә төш кенә булып дан ала. Сәйдәшев исемендәге хуҗалыкның бу бригадасы авыл хуҗалыгы тармагын үстерүгә үзеннән саллы өлеш кертә. Бирегә ат, сыер, сарык, дуңгыз асрала. Шуңа өстәп, әле тавыклар да тотыла. Гатифә Гәрәева фермалардагы малларның, тавыкларның азык рационы, сәламәтлеге һәм санитар таләпләрнең үтәлеше өчен җавап бирә.

– Хезмәт коллективында үзара дуслык, бердәмлек булмаса, эштә уңышка ирешү мөмкин түгел. Бездә башкаларга салынып, кеше эшләгәндә кул кушырып утыручы булмады. Иңне иңгә куеп эшләдек. Фани дөньядан ахирәткә күчкән хезмәттәшем Сәкинә Шәяхмәтованы искә аласым килә: тырыш терлекче булды. Бик матур истәлекләр генә калдырды үзеннән соң. Бергә җыелышканда һәрвакыт матур яктан искә алабыз, дога кылабыз. Авыр шартларда эшләдек, ул чорда тормышяшәешебездә дә уңайлыклар юк иде. Шуңа да карамастан, күңел төшенкелегенә бирелмәдек. Хәзер дә шул рухны саклыйбыз. Фәймә Сөләйманова сыер сауды, Фәгыйлә апабызга хәзер – 86 яшь, ул мал симертүдә эшләде, Фәния Гыймазова да шунда ук хезмәт куйды, Светлана Хафизова сыер сауды. Иткә симертелгән малларны Чаллы ит комбинатына трактор белән алып бара торган идек. Ул заманда юллар юк, кышын малларны трактор чанасында ташыдык. Тере мал белән эшләү – үтә җаваплы эш. Аның арасында үлем-китеме дә булмыйча тормый. Һава торышы да син дигәнчә генә булмый, корылык елларны кыш чыгарга мал азыгы җитәрлек булсын дип янасың-көясең. Шулай булса да, хезмәттән тәм, тормыштан ямь табып яшәлде. Уенкөлкегә, җыр-биюгә хирыс булдык. Сабантуйлар чын авылча оештырылып, гөрләп уза торган иде. Ел буена көч туплап кала торган, көтеп алган бик матур бәйрәм булып күңел түрендә калды, – дип, авыр хезмәт белән узган елларын сагынып искә ала Гатифә апа.

Сиксәннән өстә булса да, ул әле дә ут уйната. Утыз сигез хуҗалыктан торган авылның утыз йортында ел әйләнәсе учакларда ут сүнми. Кыш уртасында да, тәрәзә төпләрен тутырып, яраннар чәчәктә утыра. Шушы авылда яшәүче өлкәннәрне бер йодрыкка туплап тотучы, берләштерүче кеше дә ул.

Гомер буена мал-туар, терлекләр сәламәтлеген кайгырткан кешегә авылдашлары хәзер дә киңәш сорап мөрәҗәгать итәләр. Гатифә апа яшьләргә биргесез җитезлек белән ярдәмгә ашыга. Әнә берсенең терлеге хасталанган – эче китә, икенчесенең сыеры нишләптер азыкка үрелми, өченчесенең...
Дөресен генә әйткәндә, ферма мөдире – күпкырлы һөнәр иясе, ул – зоотехник та, ветеринария хезмәткәре дә, эшне оештыручы да, күпмедер дәрәҗәдә хисапчы да. Гомере буе киң колач белән эш алып барган Гатифә апа, сиксәннән өстә булса да, үз җаена гына яшәү дигәнне белми. Тиктормаслыгы, «Туры Тукай» холыклы булуы, ягъни сүзне турыдан ярып, фикерен ачык итеп әйтүен күпләр хупласа да, «чеметеп алуы» кемгәдер ошап та бетмидер. Шулай да, холкындагы гаделлеге өчен, Гатифә апаны хөрмәт итәләр. Тырышлыгы, ярдәмчеллеге, кеше яратуы, гаделлеге белән ул ил күзендә, халык теленд ә яхшы дан алган.

Зәрия ВӘЛИЕВА.
Тукай районы

БЕЗНЕҢ РӘМЗИЯ

Айның дүртендә Рәмзия килгәнне көтеп торабыз. Авылыбызның хат ташучысы ул. Рәмзия өебезгә керсә, дөньялар яктырып киткәндәй була. Тәмле телен, ягымлы йөзен кызганмый. Ә бит Рәмзиянең йөрәге тулы хәсрәт аның. Ачы хәсрәтләр күрсә дә, сынмаган, үзендә яшәү көче тапкан кеше ул.

...Чәчәктәй кызны авылдашы Миңнегали урлап өйләнә. «Мин сине мәхәббәт диңгезендә генә йөздертермен», – ди ул аңа. Кыз аның сүзләренә ышана. Яши башлагач, яратырмын әле, дип ризалаша. Тик Миңнегали хәмер белән дуслаша. Ахыр чиктә, үз-үзенә кул сала. Рәмзия улы Мәсгут белән тол кала. Балам «әти» дияргә тилмереп үсә инде, дигән чаклары да күп була аның. Әмма ире белән биш ел яшәп калган тормышы бик авыр була. Ул үз-үзенә, башка бер дә гаилә кормам, ахры, дип тә әйтә. Әмма язмыштыр, көннәрдән бер көнне үзеннән тугыз яшькә кечерәк авылдашыбыз Габделхак аңа сүз ката.

– Рәмзия апа, син дә ялгыз, мин дә ялгыз. Әллә бергә яшикме? – ди. Рәмзия аптырап кала. Яшь егетнең бу тәкъдимен уенга ала. Әмма егет сүзе бер – ул өйләнергә тели. Риза булмасаң, урлыйм, дип тә өсти. Габделхакның әти-әнисе дә Рәмзияне алдырасылары килә. Булачак киленне үгетли алар. Рәмзия ризалаша. 30 яшендә тагын ир хатыны булып яши башлый. Габделхак белән кавышкач, бер-бер артлы ике малай таба. Аларга Нияз һәм Алмаз дип исем кушалар. Тик сабыйларның гомерләре генә кыска була. Ул көнне Рәмзия эшкә китә, Габделхак балалар белән кала. Мичкә дә ягып җибәргән була. Шул чакта Габделхакның дусты килеп, тегермәндә чират та юк, ашлыгыңны алып кайтып бирәм, ди. Аларга малайларның да иярәселәре килә. Тик Габделхак кечкенә малайларны үзләрен генә калдырып, чыгып китә. Улларына кат-кат, тыныч кына утырыгыз, ди ул. Озак та үтми, Рәмзияләр урамында йорт янганын хәбәр итәләр. Фермада эштәге Рәмзия нишләргә дә белми. Җитмәсә, сезнең өй яна, диләр. Янгын көчле була. Күз алдында йорт көлгә әйләнә. Бу хәлләрне күреп торган Рәмзияне хастаханәгә алып китәләр. Әмма ул өметләнә. Сабыйларны коткарганнардыр, алар күршеләрдәдер, дип үзен тынычландыра. Тик аларның җансыз гәүдәләрен алып чыгалар.

Тегермәннән йөгереп кайткан Габделхак та бу хәлләрне күреп, бүреген салып, чәчләрен йолкып-йолкып елый. Иртәгесен сабыйларны җирлиләр. Ә аннары алар каенанасы Сания янына кайтып китәләр. Бу хәлләргә 10 ай узгач, Рәмзия кыз бала таба. Аннары инде уллары туа. Йөрәк яралары басылгандай була. Әмма бәхетсезлек тагын көтеп тора. Кинәт кенә Габделхак аягына зарлана башлый. Аяк сызлавы бетми. Габделхакның тездән аягын кисәләр. Гаилә бу авырлыкны да күтәрә. Иң мөһиме – исән-сау, дип сөенеп яши башлыйлар. Тик 5 елдан 45 яшендә Габделхак үлеп китә. Аның артыннан Сания апа да күзләрен мәңгелеккә йома. Рәмзия ике баласын алып, олы улы Мәсгут яшәгән йортка күченә. Инде Рәмзиянең балалары үзләре әти-әни булдылар. Рәмзия исә, 71 яшендә булса да, әле дә халыкка хезмәт итә. Авылыбыздагы «Зөбәрҗәт» җыр ансамбленә йөри. Без аңа карап сокланабыз. Кечкенә генә иңнәрендә күпме хәсрәт кичерсә дә, йөзендә елмаюы бетми аның. Рәхмәт сиңа, Рәмзия!

Мансур ВӘЛИЕВ.
Питрәч районы Шәле авылы

Хәбәрләр

Әле кызлар кебек

«Татарстан» совхозы поселогында гомер итүче тыл хезмәтчәне, хезмәт ветераны Нурания апа Нуруллинага 95 яшь тулды. Аны олы юбилее белән котларга район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Илфак Бариев килде. Ул юбилярга Россия Президенты Владимир Путинның котлау телеграммасын, район башлыгы Фаил Камаевның истәлекле бүләген тапшырды.

Нурания апа гомер буе крахмал заводында хезмәт куйган. Эшен һәрчак зур җаваплылык тоеп, намус белән башкарган.

Район вәкиле белән бергә Нурания апаны Князево авыл җирлеге башлыгы Фәндүс Камалов, мәдәният хезмәткәрләре, балалары һәм туганнары да котлады. Барысы да юбилярга бәхетле картлык, сәламәтлек, җан тынычлыгы теләделәр.

– Тыл хезмәтчәне буларак, Сез – Җиңүне якынайтуга зур өлеш керткән кеше. Хезмәтегез өчен рәхмәт әйтеп, алдыгызда башыбызны иябез, – диде Илфак Бариев.

Онытылган йола кайтарыла

Узган гасырның егерменче елларында халык мәгърифәткә тартыла башлагач, авылларда ызбалар (избы читальни) оештырылган. Аларга авыл яшьләре һәм өлкәннәр җыелган, укый-яза белүчеләр кычкырып матур әдәбият китаплары укыганнар. Комазан Башы китапханәчесе Мария Андреева да китапханәдә китапларны кычкырып укуны оештыра.

«Соңгы вакытта Роза Туфитуллованың «Язмыш җиле», Факил Сафинның «Биек тауның башларында», Фәнис Яруллинның «Әйтелми калган сүз» дигән китаплары игътибар үзәгендә булды», – ди ул.

Вәрис МИННЕГАЛИЕВ.
Мамадыш районы

МӘҢГӘР «АСЫЛТАШ»ЛАРЫ

Мәңгәр... Казан арты Әтнә төбәгендә ул үзенә бер аерым урын алып тора. Төзек-матур йортлары, яшеллеккә чумган урамнары, тигез юллары, ә иң мөһиме – тыныш, булган халкы белән горурланмаслык та түгел шул.

Китапханә каршында эшләп килгән «Асылташ» өлкәннәр клубына йөрүчеләрнең күбесе – авылыбызга күрше-тирә авыллардан килен булып төшкәннәр. Байтак еллар элек буйдак егетләре күп булган авылның. Әнә шул чакта килгән киленнәр бүген үзләре каенана инде, оныклар үстерәләр. Лаеклы ялга чыкканчы күмәк хуҗалыкта хезмәт куйган алар. Хәзер исә буш вакытларында Гөлшат Гарифҗанова җитәкләгән клубта очрашып, үзара аралашалар, матур кичәләр оештыралар.

2022 ел Россиядә халык сәнгате һәм матди булмаган мәдәни мирас елы дип игълан ителде. «Асылташ»ларның чираттагы очрашуы да нәкъ менә шуның кысасында узды. Кичәне Гөлшат үзе башлап җибәрде. «Казан артында энҗе-мәрҗәннәр кебек төзелеп киткән татар авылының иң матурларыннан берсе – Олы Мәңгәр авылы. Быелгы ел халыкларның гасырлардан гасырларга килүче бай мәдәни мирасын саклауга багышлана. Мәңгәр авылы гасырлар буена милли мәдәнияте һәм тыныш халкы белән дан казанган. Тарихыбызны чагылдырган китапларыбыз шул турыда сөйли. Ә менә үткән заманнар серен сеңдергән сөлгеләрдән борынгылык аңкып торадыр сыман. Аларны кулга алуыбызга вакыт тукталып калган кебек... Татар йорты бизәкләре бит алар», – дип, сөлгеләр белән таныштырды ул. Сөлге – гүзәл затларыбызның символы, татар хатын-кызының осталыгына һәйкәл.

Кәрим Тинчурин әсәре буенча «Казан сөлгесе» спектакленнән өзек тә искиткеч зур осталык белән башкарылды. Шунда ук борынгы чулпы-беләзекләр күргәзмәсе дә оештырылган иде. Андагы иң кыйммәтле экспонатлар – беләзекләр. Аларны ветераннар советы рәисе Хәлимә Закирова алып килгән. «Кулымдагы беләзегем әниемнән миңа мирас булып калды. Ә аңа әбием бүләк иткән булган. Мин исә бу беләзекне кызым Райләгә калдырачакмын. Әнә шулай буыннарны бәйләп тора ул», – ди Хәлимә апа. Яшел яшма ташлы беләзек исә – Хәлимә апаның каенанасы Сәлимә апаныкы. Ул да бик матур, бизәкләп эшләнгән. Чулпы, беләзек, калфак, читек, сөлгеләре белән элек-электән дан тоткан безнең халык. Әйткәнебезчә, аларны ясау осталык һәм түземлек таләп иткән.

Һәр милләт кешесе өчен иң моңлы көй – үзенең милли көе, иң матур, иң кадерле тел – үзенең туган теле, иң тәмле аш – үзенең милли ашлары. Өлкәннәр очрашуга үз куллары белән әзерләгән милли ризыкларны алып килгәннәр. Табын күрке – бәлеш, өчпочмак, кыстыбый, кош теле – өлкәннәребезнең уңган кулларына сокланырлык.

Әнә шундый искиткеч матур очрашу булып узды. Кулымнан килсә, мин мондый очрашуларны мәктәп укучылары белән берлектә үткәрер идем. Күңелгә үтеп керердәй, милләтебезнең тарихын чагылдырган мондый очрашулар ешрак булсын иде.

Фәридә ФИЛАТОВА

Табигать нигъмәте

Кура җиләге

Кура җиләгенең киптерелгәне дә, туңдырылганы да витаминнарын югалтмый. Салкын тигәндә киптерелгән кура җиләгеннән дә шифалырак җимеш юктыр, мөгаен. Аның составында глюкоза, фруктоза, органик кислоталар, пектин, С, D витаминнары бар. Киптерелгән җимешне, чәй пешергән кебек үк, өстенә кайнар су коеп каплап тоталар. Аны эчкәннән соң шундук җылы итеп бөркәнеп ятарга кирәк. Тир белән бергә организмнан чир дә, шлаклар да чыга.

Туңдыргычта кура җиләгенең витаминнары да шул килеш саклана. Кышкы салкын көннәрдә кура җиләге яфрагы яисә сабагы салынган хуш исле чәй эчү ямьле җәйләрне генә искә төшереп калмый, организмны да ныгыта, тонусны да яхшыртып җибәрә.

vk.com

Лимон

Туңдырылган лимон инфекцияне тизрәк җиңәргә булыша, иммунитетны көчәйтә. Ул – салкын тигәндә менә дигән дәва! Түбән температурада лимонның 90% файдалы матдәләре саклана. Диетологлар цитруслы җимешләрнең, аеруча туңдырып катырылган лимонның составын өйрәнеп, түбәндәге нәтиҗәгә килгән: ашкайнатуны нормальләштерә; кан тамырларын, бавырны, эчәкләрне чистарта; астманы дәвалый; тамак авыртуын бетерә, ОРЗ, ОРВИ вакытында температураны төшерә, көчле антисептик һәм антиоксидант; йокыны нормага сала, кан басымын җайлый; сөяк тукымаларын ныгыта; йөрәк-кан тамырлары системасы эшчәнлеген яхшырта, күзәнәкләргә кислород килүне җиңеләйтә; шешләрне киметә; авыруларны китереп чыгара торган патоген микроорганизмнарны юк итә; гельминтларны үтерә; холестеринны киметә; депрессия, көчел төшенкелегеннән коткара; азот кушылмалары булу аркасында энергия чыганагы булып тора; яман шешкә каршы торучанлыкны арттыра.

Катырганда, лимонда аскорбин кислотасы бераз кимесә дә, фосфор, кальций, калий, магний, күкерт, натрий бик яхшы саклана. Шулай ук витаминнар һәм биофлавоноидлар да сакланып кала. Диетологлар лимонны көн саен 75 грамм ашарга куша, сәламәтлеккә зыян китермичә генә ябыгып була, диләр.

vk.com

Лимонны туңдыру өчен башта аны яхшылап юалар, алма серкәсен 3:1 пропорциясендә су белән сыеклап, лимонны шунда салып торалар. Яхшылап киптерәләр. Аннары тәгәрмәчләп турап, 10–12 сәгатькә туңдырырга куялар. Алгач, угычтан уып йә иттарткыч аша чыгарып, шакмаклы бүлемле савытларга тутыралар. Лимон кабыгында цитруска караганда 5 тапкыр күбрәк витамин һәм микроэлементлар бар. Туңдырылган лимонны җимеш салатларына кушалар. Лимон телемнәрен балык, кош ите янына куялар, солянкага салалар.

Катырылган лимонны ашказаны җәрәхәте, гастрит булганда бик кулланмаска тырышыгыз. Кан басымы югары булганнарга да саграк булырга кирәк.

Сырганак

Ул – бөтен чирдән дәва. Ир-ат авырулары булганда, ашказаны авыртканда, иммун системаны ныгыту өчен кулланалар. Сырганакның җимешен кайбер авырулар күзәтелгәндә саклык белән кулланырга кирәк булса, яфрагы, кайрысы очрагында чикләүләр юк. Шуңа да сырганакның артык ботакларын кисеп, элеп киптерергә мөмкин. Аларны бакча кайчысы белән турап, яфракларын салып чәй әзерләү яхшы. Туңдырылган җимешен дә өстәсәң, бу бик тәмле эчемлек булачак.

Сырганак иммун системаны ныгыта, ялкынсынулар белән көрәшә, токсин-шлакларны чыгара, метаболизмны яхшырта, хатын-кыз авыруларын, яман шешне кисәтә, нерв системасын тынычландыра. Нәтиҗә ясап шуны әйтер идем: кешегә витаминнар күбрәк яшелчә аша түгел, җиләкләрдән керә. Шуңа да туңдырылган җиләкләрне кыш буе ашарга кирәк. Мүк җиләге, нарат җиләге, карҗиләк кибеттә туңдырылган килеш сатыла. Аларны төеп, бераз шикәр комы кушып кулланырга була, морс та бик файдалы. Нарат җиләге табигый антибиотикка тиң. Ул әче, бал салып куллансаң була.

vk.com



Нияз Бишбалта

ЖАВАПЛАР. **Горизонталь буенча:** фәрештә, фә, Алас, апа, шөһрәт, ас, рун, укү, лар, чалма, дым, ун, Гали, түбәтәй.
Вертикаль буенча: фара, талпыну, сап, сак, алаша, уч, фәс, адыгей, трап, Акмулла, Әмирхан, ни.

ТАТАРСТАН ВЕТЕРАНЫ

Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы советы һәм «Ватаным Татарстан» газетасының уртак кушымтасы.
Чыгарылыш өчен җаваплы – **Гөлгенә ШИҺАПОВА**. Биткә салучы һәм бизәүче – **Рөстәм МИҢНУЛЛИН.**

Безнең адрес: Казан шәһәре, Театр урамы, 13 й.
Телефон: 8(843) 238-16-88
Электрон адрес: soovp.kzn@tatar.ru